Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

# ТЫЛСЫМ+

Тугызынчы сан

Май, 2015 нче ел

*Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышланган махсус чыгарылыш*

## Гимназия Җиңү Язын каршылый

ГИМНАЗИЯ укучылары «Җиңү өчен бабама рәхмәт» акциясе кысаларында, Бөек Ватан сугышы ветераннарына хөрмәт, ихтирам йөзеннән, махсус бейджлар тагып йөриләр.

ГИМНАЗИЯ укучылары «Үлемсез полк» акциясенә булдым кушылдылар. Ел дәвамында һәр сыйныф коллективы сугыш һәм тыл ветераннарын барлау юнәлешендә эшләде. Бүгенге көндә 70 портрет әзерләнде. Район үзәгендә оештырылучы Җиңү парадында райондашларыбыз акция нәтиҗәсе белән таныша алачак.

ГИМНАЗИЯ укучылары «Музей язы» акциясендә актив катнаштылар.

ГИМНАЗИЯ укучылары һәм укытучылары төрле дәрәҗәдәге иҗади конкурсларда актив катнашалар. «Җиңү җыры» регионара иҗади эшләр конкурсына 5 укучының хикәя, җыр, мәкалә номинацияләре буенча эшләре җибәрелде.

ГИМНАЗИЯ укучылары, Җиңү язын каршылап, территорияне төзекләндерү, микрорайонны чистарту өмәләрендә активлык күрсәтәләр.

## 9 МАЙ - ҖИҢҮ КӨНЕ




*1941 нче елда башланган Бөек Ватан сугышы 1945 нче елның 9 нчы маенда гына тәмамлана. Нәкъ шушы көнне Германия капитуляция актына кул куя. Бу ил тарихында булган иң сөенечле көннәрнең берсе була. Кешеләр җиңү шатлыгыннан урамга агыла. 9 нчы Май кичендә Мәскәү шәһәрендә моңарчы күрелмәгән салют ясала. Шушы вакыттан 9 нчы Май дәүләт бәйрәме һәм ял көне дип игълан ителә.*

*Быел илебезгә 70 нче ҖИҢҮ ЯЗЫ килде.*

## ГИМНАЗИЯДӘ ҖАНЛЫ ОЧРАШУЛАР



Мөслим гимназиясенең актлар залында, Җиңү дәресе кысаларында сугыш ветераны Шәрипов Әхсән Әмир улы, тыл ветераны, репрессия корбаны Сөләйманова Фәгыймә Әгълетдин кызы, тыл һәм хезмәт ветераны Тимергалиева Мәрзия Мәүләветдин кызы белән очрашу булып узды. Кунаклар укучыларга сугышның авыр еллары, үзләренең тормыш хатирәләре турында сөйләделәр. Укучылар өлкәннәрне кызыксынып тыңлады, сораулар бирделәр. Парад формасына киенгән, түшләренә георгий тасмасы таккан укучылар, сәхнәгә чыгып, кунакларга "Җиңү көне" җырын бүләк иттеләр, аларга кушылып бар зал җырлады. Бөек Ватан сугышы һәм тыл ветеранынары белән очрашу югары дәрәҗәдә әзерлек белән узды. Сугыш чоры турында тулы күзаллау булдырылды.

## СУГЫШЛАР КАБАТЛАНМАСЫН!

Сугыш... Сагыш ... Нинди куркыныч, салкын сүзләр...

Сугыш дигәч тә, бөтенләй туңып китәсең. Чын сугышның нинди икәнен күрмәгәч, аны бөтен чынбарлыгы белән күз алдына китерә дә алмыйбыз. Бөек Ватан сугышын тарих дәресләре, кинофильмнар, китаплар, әби-бабайларыбыз сүзләре аша гына беләбез. Ә безнең бабайларыбыз бу канкойгыч сугышны күргәннәр, аның барлык газапларын үз йөрәкләре аша уздырып, җилкәләрендә күтәргәннәр.

Минем бабай Сафиуллин Гыйздулла Галиулла улы була. Ул сугышка кадәр укытучы булып эшли. Аңа армиягә бармас өчен бронь бирәләр, чөнки ул елларда укытучылар җитми. 27 яшьтә бабайны армиягә алалар, бу 1940 елда була. Бабай ВДВ (десант) гаскәрендә хезмәт итә. Ике тапкыр парашюттан сикерергә насыйп була. Нәкъ бер ел хезмәт иткәч, илдә сугыш башлана һәм аларны беренче булып сугышка кертәләр. Бабай шул ук елны яралана, аны Казанга госпитальгә кайтаралар. Ул анда 6 ай дәвалана һәм өченче группа инвалид булып, кабат авылга кайта.

Бабай сугыштан кайтканнан соң да мәктәптә балалар укыта.1945 нче елда бабайны кабат сугышка аласы булалар. Алар әзерләнеп повестка көтәләр, сохарилар киптереп куялар. Бәхетләренә, май аенда сугыш тәмамлана.

Әби белән алар икесе дә гомер буе укытучы булалар. Сигез бала үстереп, матур, тигез гомер итәләр. Мин бабаем белән горурланам. Сугышлар була күрмәсен! Сугыш турында алдагы буыннар кинолардан күреп кенә белә алсыннар иде.

***Ринат Сафиуллин,***
***8 нче а сыйныфы укучысы***

## УТЛЫ ЕЛЛАР АША

# ФӘРВӘҖЕТДИН БАБАМ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ



*Минем әнинең әтисе Хәйретдинов Фәрвәҗетдин Хәйретдин улы Бөек Ватан сугышында катнашкан. Туган якларына исән-сау кайтып, колхозда эшләгән. Кызганыч, миңа бабамны күрергә насыйп булмады. Гаиләбездә аның турында үзе исән вакытта язып калдырган истәлекләр саклана. Шуларны укыгач, илебез тарихы, анда минем бабамның данлы эзе күз алдына килә. Шул истәлекләр белән уртаклашырга телим.*

Мин 1921 елның 22 апрелендә Мөслим районының Иске Авыл дигән авылында Хәйретдин белән Дәрикамалның бишенче баласы булып дөньяга килгәнмен. Безнен гаиләдә 13 бала дөньяга килеп, шуның жидесе исән-сау үскәннәр: өч ир бала, калганы - кызлар.

Авылда башлангыч белем алып, Мөслимгә йөреп, жиде класс бетердем. Мәктәпне бетергәч, "Кызыл көч" колхозында төрле эштә эшләдем. 1938 елда абый янына Свердловскига барып эшкә урнаштым. Беренче тапкыр поездларны шунда күрдем. Анда ике елга якын поезд депосында вагоннар ремонтладык. Аннары кире авылга кайтып киттем.

1940 елда вербовать итеп Урта Азия ягына "Туркменнефть"кә эшкә алып киттеләр. Безнең авылдан барысы 10 кеше идек. Анда эшләгәндә сугыш чыгу хәбәрен ишеттек. Бергә килгән иптәшләр төрле участокларда эшли иде. Бер көнне шуларны күрергә киттем. Проводниктан сорап, поездның артына утырдым. Ләкин станциягә житү белән, ярамаган урынга утыргансың дип, 6 айга кулга алдылар һәм ябып куйдылар. Мин рөхсәт белән утыргач, курыкмыйча килгән идем. Законнар бик каты вакыт иде шул. Мине мәжбүри эшкә Куйбышевка жибәрделәр. 1942 нче елда кире өйгә кайтардылар. Кайтышлый военкоматка кердем. Военкоматта: “1-2 көн өендә ял ит тә юлга әзерлән”, - дип әйттеләр. 3 көннән эткәй ат белән Әгерҗегә поездга илтеп куйды, бу кыш көне иде. Шуннан туры фронтка алып киттеләр. Безне Калинин өлкәсенә жибәрделәр. Калинин фронтына миномет-артиллерия частенә 1233 нче стрелковый полкка минометчик булып билгеләндем.

Беренче сугыш ачысын Ржев шәһәрендә татыдым. Күз башларында бик каты сугышлар булды. Мин танкка каршы ата торган пушкада төзәүче идем. Бу сугышта безнең расчет дошманның байтак кына танкларын яндырды. Шуның өчен 1942 нче елның 28 нче сентябрендә "Кызыл йолдыз" орденына тәкъдим иттеләр. Шушы ук елда комсомолга алдылар. Кышны шул фронтта оборонада тордык. 1943 елның мартыннан һөҗүмгә күчтек. Мин шул ук 45 миллиметрлы минометта төзәп торучы вазифасын башкардым. Бу бик житди, җаваплы эш. Үземә ышанып тапшырылган бурычны бик яхшы беләм, чөнки минем төгәллегемнән сугыштa күп нәрсә хәл ителүен аңлыйм. Пушкаларны күбрәк үзебез тартып йөри идек. Чөнки атлар житми, аларга осколка тиеп бик күп үләләр иде. Сугышта кырылган атларны кызганып, йөрәкләрем әрни иде. Мин бит авыл малае, үзем дә ат белән эшләгән кеше. Аларның нинди кадерле булуын үзем генә беләм. Мәнә шундый хәлләр кичерергә туры килде.

Сугыш техникасы гел үзгәреп, яңарып тора. Алар бер үк принципта эшләсәләр дә, төгәллек ягыннан, сыйфат ягыннан яхшырак була бара иде. Янадан 82 миллиметрлы минометта төзәп атучы булдым. Күп бәрелешләрдә катнаштым һәм мине "За отвагу" медале белән бүләкләделәр. Сугышта бүләк турында уйланылмый, күбрәк дошманны юк итү, исән калу турында гына уйлыйсың. Сугыш тынгач, фронт командиры бүләкләр тапшырганда гына үзеңнең тырышлыгыңны күрүләренә сөенәсең, исән калуыңа тагын бер шөкер итәсең.

1943 нче елда Коммунистлар партиясенә кердем. 17 ноябрьдә яңакка осколка тиеп яраландым. Осколкасы һаман утыра әле. 1944 нче январеннан, үз телəгем белән, янадан алгы сызыкка киттем. Монда яна частька эләктем: 5 нче Сталинград фронты 2 нче артиллерия дивизионына 27 бригаданын 251 нче миномет полкына җибәрделәр. 120 миллиметрлы минометта төзәп атучы итеп билгеләделәр. Безнең часть бик зур часть булу сәбәпле, кайда каты сугышлар булса, шунда күчерәләр иде. Без Ленинград сугышына кердек.

1944 нче елның мартында аркага һәм башыма осколка кереп яраландым, контузия алдым. Без яткан госпиталь немецлар ягында чолганышта калды. Бер иптәшем атка атландырып үзебезнен якка алып чыкты. Ул безнең як - Минзәлә егете иде. Бер-беренә ярдәмләшү булмаса, сугышта бик тә начар. Әгәр мине шул егет алып чыкмаса, хәзерге бу тормышларны күрә дә алмаган булыр идем мин. Бераз йөри башлагач, тагын алгы сызыкка алып киттеләр. Бу юлы Кишинев фронтына эләктем. Румыния, Венгрия жирләрен азат иттек.

1944 нче елның 19 нчы октябрендә өченче тапкыр - шул ук сул аякка яраландым. 5 ай госпитальдән госпитальгә күчеп йөри торгач, аякка бастым һәм кире үз частема кайттым. Жиңү көнен Венгриядә каршыладым. "За победу над Германией" медале белән бүләкләндем.

Сугыш беткәч, безне Курляндиягә (Латвия, Литва) качып калган бандалардан илне тазартырга җибәрделәр. Туган авылга 1945 нче елның ноябрендә әйләнеп кайттым.

Авылга кайткач, яңа тормыш башланды. Тыныч хезмәттә үзенне күрсәтергә кирәк иде. Мин ферма мөдире һәм бригадир булып эшләдем.

*Фотода: минем бабам Хәйретдинов Фәрвәҗетдин Хәйретдин улы*

***Зарипова Алия,***
***7 нче б сыйныфы укучысы***

## УТЛЫ ЕЛЛАР КАЙТАВАЗЫ

# ГАИЛӘ ФОТОАРХИВЫ: БЕР ФОТОНЫҢ ТАРИХЫ



Кемнәрдәдер журналлар күп, кемнәрдәдер элекке маркалар, ә бездә фоторәсемнәр гаҗәеп күп... Аларны күрсәң - шаккатырсың! Әти дә, әни дә, әби-бабай да – барысы да кулларына төшкән саен карыйлар шуны... Аңламыйм: бер кат карап чыккан әйберне ник йөз кат карарга инде?!

Беркөнне кунаклар килде. 4 яшьлек апаем Алия бөтен өйнең астын-өскә китерде, һәм фотоальбом да, үз чиратында, өлешсез калмады... Фотолар залдан кухняга кадәр чәчелгәннәр иде. Апа - студент, Казанда укуда, димәк, боларны миңа җыярга туры килә... Әкрен генә һәрберсен карый-карый, альбомга тутыра барам... Менә монысында – мин. Мескен песине куып тотып, койрыгын кысып төшкәнмен... Монда әти. Үзе аткан куян тотып төшкән... Ә бу кем?

Охо! Карале, күкрәгендә медальләре дә бар! Бигрәк иске фотосурәт... Мең ел элек төшкән, диярсең. Ә фотодагы абый – таныш та, таныш түгел дә. Альбомга тыгып куймакчы идем, күзем фотоның артындагы ике хәрефкә төште: “К.И.”. О-о-о, булды бу, моның кем икәнен ачыкларга кирәк инде. Бүген үк ачыклап бетермәсәм, исемем Динар булмасын! Шулай итеп, әбинең пыяласыз күзлеген, апаның кара эшләпәсен киеп утырам, Шерлок Холмс кебек...

“К” - Кирамовтыр инде, безнең нәселдә “К” га башланган башка фамилия юк бугай. Тә-ә-әк... Димәк, әбинең этисе! Аның исеме ничек булган әле? Оныттым. Әбигә шалтыраттым, Идрис бабай икәне ачыкланды. Булды бу! Кирамов Идрис! Булды, күзлекне салып ыргыттым, эшләпәне шкафка аттым, фотоны кире җыеп куям хәзер... Бигрәк тиз ачыкланды! Туктале, кызы-ы-ык... Ә бу медален ни өчен биргәннәр икән? “Йолдыз”ы да балкып тора. Идрис бабай бик яшь күренә, ә инде нинди исемнәргә лаек булган... Кашларын да бик кызык итеп борып куйган, маңгаенда - сырлар, йөзе җитди күренә, мөгаен, язмышы бал да май булмагандыр...

Кулыма ручка-блокнот алып, яңадан пыяласыз күзлек һәм апаның эшләпәсен киеп, тизрәк телефонга үрелдем...

Әби әллә минем шалтыратуны гына көткән инде – этисе (минем дәү бабай була) турында рәхәтләнеп сөйләде белгәннәрен... Әби бик кирәкле “информация” бирде, әмма бу гына ә-әз... Әбинең бертуган сеңлесенә шалтыраттым. Баксаң, Рәмилә апада дәү бабай турында берникадәр истәлекләр дә бар икән, миңа шундый “факт”лар кирәк тә иде инде. Бөтен мәгълүматны җыйгач, минем батыр дәү бабайның авыр да, сынаулы да, сокландыргыч та тормыш юлы күз алдыма килеп басты...

Идрис бабай 1914 нче елда Мөслим районы Салавыз-Мухан авылында туа. Гаиләдә 7 бала булалар. Әйбәт кенә тормыш итәләр, үзләрен чын эш кешеләре итеп күрсәтәләр. Күп тә үтми, Олы Чакмак авылының Әсмабикә исемле кызына өйләнеп тә куя.

Ә аннары – сугыш башлана. Дәү бабай сугышка китә.

1941нче ел. Ул башта Владимир шәһәрендәге хуҗалык ротасында хезмәт итә. Ике якта хатлар йөри.

1942 нче ел. Смоленск, Орлов юнәлешендәге сугышларда катнаша. Аннан соң Волгоград камалышы... Идрис бабай анда да була... Кыска-кыска гына булсалар да, хатлар җибәреп тора.

1943 ел. Смоленск, Орлов юнәлешендә, ә көзен Полтава, Чугуевск, Киев юнәлешендәге сугышта катнаша.

1944 нче ел. Харьков, Житомир шәһәрләре өчен барган сугышларда катнаша. Варшаваны дошманнан азат иткән өчен рәхмәт кәгазе һәм “За освобождение Варшавы” медале белән бүләкләнә.

1944 нче ел, 14 нче сентябрь. Праганы азат итәләр. Дәү бабай рәхмәт кәгазе һәм медаль белән бүләкләнә.


1945 нче ел, апрель. Берлинга һөҗүм башлана. Берлинны алган вакытта да күп кенә рәхмәтләр белдерелә. Идрис бабайның күкрәген медальләр һәм орденнар бизи. Менә алар: ”За взятие Берлина”, ”За доблестный труд в Великой Отечественной войне (1941-1945 года)” һәм аеруча дәрәҗәле булган “Кызыл Йолдыз” ордены белән бүләкләнә. Ә хатларда - җиңү өмете.

Менә нинди зур сугыш юлын үткән минем дәү бабай.

Ниһаять, 1945 нче елның ноябрь аенда ул туган авылына әйләнеп кайта. Аннары исә колхозда тырышып хезмәт куя, кызы Рәйсә, ягъни минем әби туа. Аннары Ирсал абый, Рәмилә апа, Фазыл абый. Кечкенә балалар, өйдә беркем дә булмаганда, этиләренең (минем дәү бабайның) бүләкләре тутырылган тартманы алып, медаль-орденнары белән уйнап, рәхмәт хатларын кат-кат укый торган булганнар.

Ни кызганыч, 1967 нче елда дәү бабай каты авырудан вафат була.

Ләкин! Мин бит XXI гасыр баласы! Интернет белән дә хәтәр дуслыгыбыз бар. Әллә каян гына podvignaroda.mil.ru сайтын чокып чыгардым, бабайның исем-фамилиясен яздым, һәм бик кызыклы мәгълүматлар таптым. Менә аның турында ниләр язганнар: ***“В наступательных боях проявил себя смелым, инициативным, знающим прекрасно свое дело шофером. Работа его отличается абсолютной безаварийностью. Экономичен в расходе горючего и смазочных материалов. В назначенные пункты прибывает всрок. Его машина прошла 10000 км без единой аварии и поломки. На своей машине перевозит имущество связи и личный состав отделения связи. Точной доставкой связи в назначенные пункты обеспечивает бесперебойность управления полком”.*** Моның өчен аңа Кызыл Йолдыз Ордены бирелә.



Әле бу гына да түгел, дәү бабай турында икенче бер чыганакта болай дип язылган: “***Товарищ Кирамов работал шофером в Взводе Управления с марта месяца 1943 года, показал себя дисциплинированным, смелым, мужественным бойцом. Любезно и заботливо относится к своей автомашине. Всегда содержит её технически исправной и чистой, готовой к немедленному выполнению боевой задачи. Исполнителен, чуток и отзывчив к товарищам. Пользуется деловым авторитетом среди личного состава взвода. Партии Ленина - Сталина и Социалистической Родине беззаветно предан”.*** Ә моның өчен аңа “За боевые заслуги” дигән медаль бирелә.

Мин Идрис бабаем белән чын күңелдән горурланам!

Менә шулай... Ә бит барысы да гади бер фотодан башланып киткән иде... Әйбәт булды әле, берәр вакыт Бөек Ватан сугышы турында инша язарга кушсалар, Идрис бабай турында язармын...

*Фотода: Минем дәү бабам Идрис Кирамов.*

***Гыйздәтов Динар,***
***7 нче а сыйныфы укучысы***

## ХӘТЕРЛӘРНЕ ЯҢАРТЫЙК

### БАБАМ ТУРЫНДА ИСТӘЛЕКЛӘР



**Мин -** Хәниева Камилә, Мөслим гимназиясенең 9 нчы сыйныф укучысы. Бөек Ватан сугышы тәмамлануга 70 ел тулган көннәрдә үзебезнең нәселдән бу сугышта катнашкан туганнарыбызны барларга алындым. Шактый эзләнергә туры килде. Моңа кадәр үз туганнарым, нәселем турында кызыксынмавым өчен оят булып китте. Бу язмамда телгә алынган туганнарыма догаларыбызбарып ирешсен иде. Менә алар: **әни яклап бабай -** Арсланов Хәким Муллагали улы; **бабайның әтисе -** Арсланов Муллагали Арслан улы; **бабайның әнисе –** Муллагалиева Сабира; **бабайның абыйсы –** Арсланов Мирзагаян Муллагали улы; **бабайның апае –** Арсланова Мөнәвирә Муллагали кызы.

Минем Хәким бабай 1930 нчы елның 11 нче ноябрендә Баек авылында туа. Аларның гаиләсендә биш бала була. Сугышның беренче елларында гаилә әтиләреннән калган муллык белән көн күргән. Әмма 1943 нче елда ачлык вакытларында Хәким бабайның әнисе һәм ике бәләкәй апае агуланган башак ашап үләләр. Бу вакытта Мирзагаян абыйсы сугышта була. Әтисе – дәү бабаем Муллагали 1942 нче елда хәбәрсез югалган. 11 яшьлек Хәким бабам үзенең бәләкәй апае - Мөнәвирә әби белән ятим кала. Сугышка кадәр әтиләре исән вакытта алар бик яхшы яшәгән булалар: умарталары булган, ат тотканнар, сыерлар асраганнар. Ләкин 1941 нче елның август аенда Муллагали бабай сугышка китә һәм яшәү авырлаша. Бәләкәй чаклары бик авыр уза, чөнки өйнең мичен җылыту, ашарга эзләү – алар өчен зур эш була. 1945 нче елда Мирзагаян бабай колхозга хат яза. Анда үзенең апайлары авыр яшәгәне турында хәбәр итә һәм хөкүмәттән аларга ярдәм сорый. Шулай итеп, бабаем белән аның апае сугыш чорларын бер таныш кешеләрдә яшәп, икенчесенә күчеп үтәләр. 13 яшеннән басуда ат җигеп эшләгән дәү бабам. Бу турыда әнием, аның бертуган апалары истәлекләреннән белдем. Бер апабызда дәү бабабызның сугыш чорында алган Рәхмәт хатлары саклаган икән. Таушалып беткән, инде хәрефләре җуела башлаган язулар... Аларны кулыма алгач, сугышның бөтен дәһшәте күз алдыма килде. Боларны кадерләп сакларга, үзебездән соңгы буыннарга тапшырырга иде. Тагын да күбрәк беләсем килеп, төрле сайтлардан дәү бабам турында мәгълүматлар эзләдем.

Бабайның әтисе - 1897 елда туган Арсланов Муллагали Арслан улының хәрби карточкасын табуга ирештем. www.kremnik.ru сайтында аның 1942 нче елда хәбәрсез югалуы турында теркәлгән.

Сугыш чоры, аннан соңгы елларның авырлыклары, мохтаҗлыклар турында без өлкәннәрдән ишетеп кенә беләбез. Кабат сугышлар булмасын! Җирдә тынычлык, муллык хакимлек итсен!

*Фотода бабайның абыйсы – Арсланов Мирзагаян Муллагали улы.*

***Хәниева Камилә,***
***9 нчы б сыйныфы укучысы***

### Булмасын сугышлар!




Ишек төбендә баскычта,
Бабам утыра уйланып.
Җиңү көннәре житкәндә,
Сагышлардан моңаеп.

Күз алдыннан бабамның
Күпме кайгылар узган,
Шулай да җиңү өметен
Барыбер югалтмаган.

Сугышта үлем белән
Ул күзгә-күз очрашкан,
Күпме якын дусларын
Яу кырында югалткан.

Дошманнарны җиңү өчен,
Атакага барганнар.
Безнең тыныч тормыш өчен,
Гомерләрен биргәннәр.

Еллар уза барган саен,
Сирәгәя бара сафлары.
Исәннәрнең кадерен белеп,
Олылыйк без аларны.

Мин телим бу дөньяда
Булмавын сугышларның,
Кешеләрнең жир йөзендә
Шатланып яшәүләрен.

***Мәгъдәнова Ләйсән,***
***7 нче а сыйныфы укучысы***

ТЫЛСЫМ+
Май, 2015 нче ел
*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Исмәгыйлева Язилә
**Корректор:** Мөхәммәтханова Айгөл
**Корреспондентлар:** Мәгъдәнова Ләйсән
Хәниева Камилә
**Дизайнер:** Галиев Илназ

**Компьютерда җыючылар:** Гилемов Азат
Ринат Сафиуллин
**Гамәлгә куючы:**
Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym